## Казан–Түбән Новгород-Казан маршруты буенча «Тихий Дон» теплоходында сәяхәт

2023нче елда профессионал бәйге муниципаль этабында җиңүчеләр - Балтач гимназиясенең сыйныф җитәкчесе Мостафина Венера Әмировна, рус теле укытучысы, «Ел укытучысы» бәйгесенең Гран-при иясе Мәхмүтова Гөлнар Илдаровна 17-19нчы май көннәрендә мәгариф хезмәткәрләре профсоюзының республика комитеты тарафыннан оештырылган Казан–Түбән Новгород-Казан маршруты буенча «Тихий Дон» теплоходында сәяхәт белән бүләкләнделәр. Сәяхәт барышында укулар, танышу, экскурсияләр булачак.

